**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 25 май № 298

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында» 2016 ел, 14 апрель, 223 нче карар белән расланган Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында» 2016 ел, 14 апрель, 223 нче карар белән расланган Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе (алга таба – премия) соңгы биш елда, әмма премия алырга дәгъва иткәнче бер елдан да соңга калмый басылып чыккан, әдәбият (шигърият, проза, әдәби тәрҗемә) өлкәсендә киң җәмәгатьчелектә танылу тапкан, рус телендә иҗат ителгән күренекле әсәрләре өчен һәм Г.Р.Державин иҗатын популярлаштыра торган татар телендә әсәрләре өчен язучыларга, шагыйрьләргә, тәрҗемәчеләргә, һәм юриспруденция өлкәсендә фәнни тикшеренүләре (монографияләре) өчен юристларга бирелә (алга таба – эшләр).»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Премия елга бер тапкыр, һәрберсе 200 сум күләмендә ике премия рәвешендә бирелә, берсе – әдәбият өлкәсендә һәм икенчесе – юриспруденция өлкәсендә.»;

4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Премия алуга аерым авторлар, шулай ук сигез кешедән артмаган авторлар коллективы башкарган эшләр чыгарыла.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Премия алуга эшләрне чыгару Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, оешмалар (шул исәптән фәнни һәм иҗтимагый оешмалар, югары белемнең мәгариф оешмалары, театрлар, музейлар, китапханәләр, мәдәни-

ял оешмалары), җирле үзидарә органнары (алга таба – оешма) тарафыннан башкарыла. Эшләр коллегияләр, президиумнар, секретариатлар, фәнни һәм сәнгати советлар утырышларында, оешманың хезмәт коллективлары һәм бүтән коллегиаль органнары җыелышларында чыгарыла.»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Премия алу өчен эшләрне сайлап алуның түбәндәге критериеләре билгеләнә:

әдәбият өлкәсендә:

эшнең югары әдәби дәрәҗәсе (0 – 10 балл);

Татарстан Республикасында әдәбиятне үстерү өчен эшнең актуальлеге һәм әһәмияте (0 – 10 балл).

юриспруденция өлкәсендә:

эшнең фәнни яңалыгы (0 – 10 балл);

юриспруденция өлкәсендә эшнең гамәли әһәмияте (0 – 10 балл).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин